ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.03.2023 Балык Бистәсе штп. № 57пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының "Педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә билгеләү турында" 2019 елның 12 ноябрендәге 272пи номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә дәүләт ярдәме күрсәтү һәм педагогик кадрларны беркетү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Педагогик хезмәткәрләргә-яшь белгечләргә айлык стимул өстәмәләрен билгеләү турында» 29.12.2018 ел, №1214 карарына үзгәрешләр кертү турында» 15.11.2022 ел, №1214 карарына таянып карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә ай саен өстәмә түләүне билгеләү турында» 2019 елның 12 сентябрендәге 272пи номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта "1 111 сум " сүзләрен «2 510 сум» сүзләренә алыштырырга;

Татарстан Республикасы бюджетыннан Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 5 пунктындагы 5 абзацында Татарстан Республикасы муниципаль мәгариф оешмаларында эшләүче педагогик хезмәткәрләргә-яшь белгечләргә айлык стимуллаштыру өстәмәсен түләүгә "1111 сум" сүзләрен "2 510 сум" сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы" нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге" муниципаль казна учреждениесе житәкчесе И.М. Садыйковка йөкләргә.

Житәкче Р.Л. Исланов